Муниципальное бюджетное дошкольное образовательное учреждение
«Детский сад общеразвивающего вида №7» муниципальное образование
«Лениногорского муниципального района» Республики Татарстан

Принято
педагогическим советом
протокол № 1от «29» августа 2024г.

«Утверждаю»
Заведующий МБДОУ «Детский сад №7»
___________________Л.Р.Билалова
Введено в действие приказом
от «29» августа 2024г. №76/ПД

# Рабочая программа
# по обучению татарскому языку
# детей дошкольного возраста (4 - 7 лет)
## на 2024 – 2025 учебный год

**Воспитатель по обучению детей татарскому языку:**
Гайнутдинова Аймара Марсиловна,
высшая квалификационная категория

г. Лениногорск, 2024г.

| I НЧЕ БҮЛЕК. Максат | | Бит |
|---|---|---|
| 1. | Аңлатма язуы | 3 |
| 1.1 | Программаның максаты һәм бурычлары | 4 |
| 1.2 | Программа принциплары | 5 |
| 1.3 | Балаларның яшь үзенчәлекләре | 5 |
| 1.4 | Программа үзләштерүдә көтелгән нәтиҗәләр | 5 |
| 1.5 | Уртанчылар төркеме (4-5 яшь) | 6 |
| 1.6 | Зурлар төркеме (5-6 яшь) | 8 |
| 1.7 | Мәктәпкә әзерлек төркеме (6-7 яшь) | 8 |
| **II НЧЕ БҮЛЕК. Эчтәлек** | | |
| 2.1 | Эш төрләре һәм формалары | 9 |
| 2.2 | Инновацион  эш | 10 |
| 2.3 | Ата – аналар белән үзара эшчәнлек планы | 11 |
| 2.4 | Коррекция эше | 11 |
| **III НЧЕ БҮЛЕК. Оештыру** | | |
| 3.1 | Материаль – техник яктан тәэмин ителеш | 17 |
| 3.2 | Предметлы – үстерелешле  әйләнә - тирәлек | 17 |
| 3.3 | Программалар белән һәм методик  яктан тәэмин ителеш | 22 |

# I НЧЕ БҮЛЕК. Максат
## 1.Аңлатма язуы.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә кабул ителгән 2010 – 2015 елларда мәгарифне үстерү стратегиясендә (30.12.2010, №1174) – мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү учреждениеләре өчен рус һәм башка милләт балаларын татарча сөйләшергә өйрәтү программасы, укыту-методик комплектлары (УМК) төзелде.

Программа 4 яшьтән 7 яшькә кадәр булган рус телле балаларның татарча аралашырга өйрәтү эшчәнлекләрен, "Минем өем" (4-5 яшь), "Уйный – уйный үсәбез" (5-6 яшь), "Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар" (6 - 7 яшь) проектларын үз эченә ала. Программа мәктәпкәчә яштәге баланың үсеш закончалыкларына, шәхси һәм эшлекле якын килү турындагы фундаменталь тикшеренүләргә, тел өйрәтү процессында методик стандарт итеп кабул ителгән коммуникатив технология принципларына, сөйләм барлыкка килү концепциясенә (Л. С. Выготский, В. В. Давыдов, Е. И. Пассов, П. Я. Гальперин), гамәли эшкәртмәләр һәм методик киңәшләргә, мәктәпкәчә мәгариф системасы эшчәнлеген ачыклаучы норматив хокукый актлар, нигезләмәләренә көйләнгән.

Балаларны татар телендә сөйләшергә һәм аралашырга өйрәтү билгеле бер күләмдәге сүз байлыгы булдырудан башлана. Аралашуга чыгу өчен нәтиҗәле чаралар булып аудиоязмалар, эш дәфтәрләре, анимацион сюжетлар, интерактив уеннар тора.

Яңа сүз өйрәткәндә, сүзләр тизрәк истә калсын өчен сүз кат-кат әйттерелә, аңлашылмаган очракта, аның русча тәрҗемәсе бирелә; төрле эш формаларында (пышылдап, күмәкләп, төркемнәргә бүленеп, хәрәкәтләнеп әйтеп) өйрәтелә; уеннар кулланып ("Ватык телефон", "Кайтаваз"...) ныгытыла; хәтердә калдыру максатыннан төрле уеннар оештырыла: "Исемен әйтсәң бирәм", "Мин күрсәтәм, син әйт", "Сорап ал", "Серле кәрзин".

Өйрәнгән лексиканы сөйләмдә кулланганда "Бу кем?", "Кем юк?", "Кәрзиндә нәрсә бар?", "Нәрсә юк?", "Серле янчык", "Әйе-юк", "Дөресен әйт" дидактик уеннары уйнала.

Аралаша белү күнекмәләре булдырганда "Әйдәгез танышабыз", "Кунакны сыйла", "Кибеттә", "Кафеда", "Телефоннан сөйләшү"уен ситуацияләре оештырыла.

Пиктограммалар мәктәпкә әзерлек төркемендә, яңа сүзләр (фигыльләр) белән беренче тапкыр таныштырганда гына кулланыла.

Тәрбияче сүзлек белән эшләгәндә татар һәм рус телләре өчен уртак сүзләргә таяна ала.

Укыту-методик комплекты кысаларында, лексик минимумны үзләштергән очракта, эшчәнлектә планлаштырылган уеннарның эчтәлеген үзгәртү, яңа алымнар кертү, баету хуплана.

Төркемнәрдә балаларның һәм тәрбиячеләрнең татар телендә аралашулары һәрдаим булырга тиеш. Эшчәнлектә өйрәнелгән тел материалы, режим моментларында, уен эшчәнлеге аша (ситуатив күнегүләр, сюжетлы рольле уеннар, үстерелешле диалоглар, сәхнәләштерү һ. б.) ныгытыла.

Рус телле балаларны татарча сөйләшергә өйрәткәндә балалар бакчасы коллективы һәм әти-әниләрнең бердәм позициядә булуы уңай нәтиҗә бирә.

## 1.1 Программаның максаты:

Информацион – коммуникатив технологияләр, уен – ситуацияләр, күргәзмәлелек кулланып, тел өйрәтү, аралашу теләге тудыру.

**Уртанчылар төркеме (4-5 яшь)**
**“Минем өем” проекты**

**Белем бирү эшчәнлегенең бурычлары:**

1. Бер – береңне тыңлау, ишетү сыйфатлары тәрбияләү.
2. Тирә- юнь күзаллавын киңәйтә барып, иң якын кешеләре, уенчыклар, ашамлыклар хисабына сүз байлыгын арттыру.
3. Тәрбияче кушкан катлаулы булмаган биремнәрне аңлап үти, кыска фразаларны кабатлап әйтә белүләренә ирешү.
4. Гади диалогта катнаша белү, хәтер, зиһен сәләтләрен үстерү.

**Зурлар төркеме (5-6 яшь)**
**“Уйный – уйный үсәбез” проекты**

**Белем бирү эшчәнлегенең бурычлары:**

1. Әдәпле итеп кара-каршы сөйләшә белү күнекмәләрен тәрбияләү.
2. Тирә- юнь күзаллавын киңәйтә барып, яшелчәләр, савыт-сабалар, киемнәр, өй җиһазлары, ашамлыклар темасына кергән сүзләр хисабына сүз байлыгын арттыру.
3. Үзара һәм зурлар белән көндәлек тормышта татарча аралашуга чыгуларына ирешү.
4. Сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә камилләштерү.
5. Диалогик сөйләмне фикер йөртү, хәтер, зиһен сәләтләрен үстерү.

**Мәктәпкә әзерлек төркеме (6-7 яшь)**
**“Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар”проекты**

**Белем бирү эшчәнлегенең бурычлары:**

1. Сөйләм әдәбе (сорау, гозер, мөрәҗәгать итү, рәхмәт белдерү, исәнләшү, саубуллашу) кагыйдәләрен камилләштерү , балада үзенең сөйләме белән кызыксыну һәм сизгерлек уяту.
2. Ашамлыклар, кыргый хайваннар, кошлар, мәктәп темасына кергән сүзләр хисабына баланың сөйләмен баету, тулыландыру.
3. Сөйләмне аралашу чарасы буларак камилләштерү, файдалана белү күнекмәләренә өйрәтү, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белергә күнектерү.
4. Диалогик һәм монологик сөйләмне, фикер йөртү, хәтер, зиһен сәләтләрен үстерү.

## 1.2 Программа принциплары.

*Коммуникативлылык принцибы* – балаларны татар телен аралашу чарасы буларак куллануга әзерләүгә корылган. Телне фән буларак түгел, ә аралашу чарасы буларак өйрәтү;

*Тел өйрәтү, тәрбия һәм үстерү бурычларының бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә тормышка ашыру принцибы;*

*Дәвамчанлык принцибы* – балалар бакчасы һәм башлангыч мәктәптә эзлеклелекне күздә тоту;

*Белем бирү эшчәнлегенең мотивлашкан булу принцибы* - бала материалны үзе өчен кызык булганда, үзенең шәхси ихтыяҗларына туры килгәндә генә кабул итә һәм фикерли башлый. Телне өйрәтү процессында әкияти сюжетлар карау, кызыклы таныш геройлар (Акбай, Мияу) белән очрашу, уен элементларын куллану – тел материалын өйрәнүнең мотивлашкан булуын тәэмин итә. Телне аралашу, уен ситуацияләренә бәйләп өйрәнгәндә, балалар тел өйрәнүнең практик әһәмиятен тоялар, эмоциональ күтәренкелек туа һәм алар тел материалын бик теләп үзләштерәләр.

*Индивидуальләштерү принцибы* - тел өйрәткәндә социаль шәхес сыйфатларын үстерүне күздә тоту. Балаларның яшь үзәнчәлекләрен исәпкә алу.

*Күрсәтмәлелек принцибы* – тел өйрәтүне көндәлек тормыштагы һәр төрле эшчәнлеккә бәйле рәвештә, аларның тирә-юньне танып белүенең төп чарасы булып торган уен аша үткәрү.

*Интеграция принцибы* – һәр сөйләм торенең үз үзәнчәлеген исәпкә алу, тәрбияче сөйләмен техник чаралар ярдәмендә (аудио, видеоязмада) тыңлау (аудирование), тел үзәнчәлекләрен төрле күнегүләрдә бирү, балаларның диалогик сөйләмен үстерү.

## 1.3 Балаларның яшь үзенчәлекләре

### Уртанчылар төркеме (4-5 яшь)

Бу яшьтә баланың өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән аралашуда мөстәкыйльлеге үсеш ала. Балалар өлкәннәр белән практик эшләрдә (йомыш үтәү, кумәк уеннар) аралашуны дәвам итү өстенә интеллектуаль аралашуга да омтылалар. Бу күпсанлы сораулар (Нигә?, Ни өчен?, Нәрсә өчен?) бирүдә һәм өлкәннәрдән яңа информация алырга теләүдә күренә. Балаларның сүзлегендә теләктәшлек, кеше хәленә керә белү, кызгану сүзләре барлыкка килә. Яшьтәшләрен үзләренә җәлеп итү өчен балалар аралашуның ситуациясенә карап, интонация, ритм, сүз тизлеген җайлыйлар. Өлкәннәр белән аралашу вакытында сөйләм этикеты кагыйдәләрен үтәп, исәнләшү, саубуллашу, рәхмәт әйтү, гафу үтенү, юату, кызгану, кеше хәленә керә белү сүзләрен кулланалар. Бу яшьтә баланың сөйләме бәйләнешле һәм эзлекле була.

### Зурлар төркеме (5-6 яшь)

Алтынчы яшьтә баланың сөйләм үсешендә мөхим үзгәрешләр барлыкка килә.

Авазларны дөрес әйтү бу яшьтә норма булып тора. Балаларда (чит телгә), татар теленә карата кызыксынулары арта, шул телдә сөйләшергә, җырларга, аудио – видеоязмалар тыңларга, телевизион тапшырулар карарга теләкләре үсә. Балалар сөйләмдә гомумиләштерүче, күпмәгънәле сүзләр, антонимнар, синонимнар куллана башлыйлар. Аларның сүзлеге профессияне, социаль учреждениеләрне аңлатучы сүзләр, фигыльләр, сыйфатлар хисабына баетыла. Балалар сөйләм әдәбе кагыйдәләрен өйрәнеп, мөстәкыйль

рәвештә уенлы һәм эшлекле диалоглар төзергә, туры һәм кыек сөйләмне кулланырга өйрәнәләр, тасвирлау һәм хикәяләү монологында геройның хәлен, кәефен, эпитетлар һәм чагыштырулар кулланып, бирергә сәләтле. Балалар үзара кара – каршы сөйләшергә, үзләренә юнәлгән сөйләмне аңларга һәм шулай ук тиешле репликаны кулланып җавап бирергә сәләтлеләр. Бу яшьтәге балалар уен ситуацияләре, проблемалы – эзләнүле уен ситуациләрен барлыкка китереп, күрсәтмә әсбаплар, мәгълүмати – аралашу технологияләрен кулланып аралашырга өйрәнәләр.

**Мәктәпкә әзерлек төркеме (6-7 яшь)**

Бу яшьтә баланың сөйләме төрле контингет кешеләре (өлкәннәр һәм яшьтәшләре, таныш һәм таныш булмаган кешеләр) белән аралашуга мөмкинлек бирә. Балалар авазларны дөрес әйтү генә түгел, фонемаларны һәм сүзләрне таныйлар. Телнең орфологик системасын үзләштерү аларга исемнәрнең, фигыльләрнең һәм сыйфатларның катлаулы грамматик формаларын төзергә мөмкинлек бирә. Чит телгә карат тотрыклы кызыксыну үсә. Мәгълүмати – аралашу технологияләрен кулланып аралашырга өйрәнәләр, аудио – видеоязмалар, уку – укыту методик комплектларын кулланып предметны, аның билгесен, хәрәкәтен белдерүче сүзләрне һәм сүзтезмәләрне сөйләмдә, аралашуда актив кулланалар. Гади аралашу өчен кирәк булган сөйләм берәмлекләре белән балаларның лексикасы баей, сүз байлыклары арта.. Бу яшьтәге балалар төзелеше ягыннан катлаулы булмаган хикәя һәм сорау җөмләләр төзиләр. Татар телендә сөйләшүче әңгәмәдәшенең сөйләмен тыңлый белергә, нәрсә турында сөйләгәнен аңларга тырышалар. Телне аз белүләренә дә карамастан диалогларда катнашырга омтылалар. Мәктәпкә әзерлек төркеме балалары бик еш сөйләмдә катлаулы җөмләләр кулланалар. 6—7 яшьтә баланың сүз байлыгы арта. Диалог төзегәндә бала сорауларга тулы җавап бирергә, үзе сораулар бирергә, әңгәмәдәшен аңларга тырыша. Монологик сөйләм дә актив рәвештә үсә. Балалар эзлекле һәм бәйләнешле итеп сөйли алалар.

## 1.4 Программа үзләштерүдә көтелгән нәтиҗәләр

### 1.5 Уртанчылар төркеме (4-5 яшь)

### “Минем өем” проекты

**Лексик минимум** – якынча 62 сүз. “Минем өем” проекты темалары ( “Гаилә”,“Ашамлыклар”,“Уенчыклар”,“Саннар”) буенча бирелгән лексиканы төрле ситуацияләрдә ишетеп аңлап куллана белергә өйрәтү, сөйләм күнекмәләрен булдыру.

Аларның тирә-юнь кузаллавын киңәйтә бару, югарыда күрсәтелгән темага караган сүзләр хисабына балаларның сүз байлыгын арттыру өстендә эшләү, аларда татар телендә сөйләшә башлау теләге уяту.

Актив үзләштерүләренә ирешү өчен әйбер исемнәренең мәгънәсен аңлату һәм аларны дөрес әйтү күнегүләре эшләү. Иң якын кешеләр (*әти, әни, бабай, әби, малай, кыз)*, яраткан уенчыклар (*туп, машина, курчак, эт, песи куян, аю),* ашамлыклар *(алма, ипи, сөт, чәй)* һәм саннар *(бер, ике, өч, дүрт, биш)* хисабына сүзлекне баету һәм активлаштыру. Өйрәнгән сүзләрне аерым, күмәк, тәрбияче ярдәмендә кабатлый белү күнекмәләрен булдыру. *Алма бир. Мә, алма*.

Бу кем? Бу нәрсә? сорауларын аңлап җавап бирергә өйрәтү.

-*Бу кем? – Бу әти.*

-*Бу нәрсә? – Бу туп.*

Нинди? соравын аңларга, дөрес җавап бирергә өйрәтү.
-*Туп нинди? – Кечкенә.*
-*Машина нинди? – Матур.*
Әйбернең билгесен ачыклау максаты белән куела торган сорауларны аңларга һәм сөйләмдә җавап кайтарырга өйрәтү. (Зур, матур, кечкенә, чиста, әйбәт, пычрак, тәмле).
-*Бу нәрсә? – Бу туп.*
-*Туп нинди? – Туп пычрак (зур, матур, кечкенә, чиста, әйбәт).*
Тәрбияче әйткән сүзләрне, кыска фразаларны балаларның кабатлап әйтә белүләренә ирешү өстендә эшләү. Аларның өлкәннәр кушкан катлаулы булмаган биремнәрне аңлап, үти белүләренә ирешү *(мә, бир, утыр, аша, эч, уйна, ю, ал).*
-*Мә, куян. – Бир куян.*
Тәрбияче әйткән билге буенча предметны табу, күрсәтә белергә өйрәтү.
*Зур машина ал. Тәмле алма бир.*
Үз исемен дөрес әйтә, исәнләшә, саубуллаша белергә өйрәтү, сүзләрне дөрес, урынлы куллану.
*Исәнме. – Исәнмесез. Сау бул. – Сау булыгыз. Мин кыз. - Мин Оля. Мин малай - Мин Коля.*
Таныш предметларның исемнәрен ныгыту, куелган сорауга раслаучы, инкарь итүче сүзләрне *(әйе, юк)* дөрес кулланырга өйрәтү
*Син Коля? – Әйе.*
*Син кыз? – Юк, мин малай.*
Мин, син алмашлыкларын аңларга һәм урынлы кулланырга өйрәтү.
*Син кем? – Мин Коля.*
Кечкенә күләмле шигырьләр, җырлар өйрәтү.

**Белем бирү эшчәнлегенең нәтиҗәләре**

Гаилә, уенчыклар, ашамлыклар һәм саннар хисабына сүз байлыгы бар.
Өйрәнгән сүзләрне, кыска фразаларны аерым, күмәк, тәрбияче ярдәмендә кабатлый белә.
Өлкәннәр кушкан катлаулы булмаган биремнәрне аңлап үти.
Үз исемен дөрес әйтә, исәнләшә, саубуллаша, рәхмәт әйтә белә.
Куелган сорауларны аңлап, сөйләмдә 2-3 сүз белән җавап кайтара белә.
Бер-берсе һәм өлкәннәр белән 62 сүз кулланып татар телендә аралаша.
Бирелгән лексиканы төрле ситуацияләрдә ишетеп аңлап куллана белә, сөйләм күнекмәләре бар.
Әйбер исемнәренең мәгънәсен аңлый һәм аларны дөрес әйтә белә.
Бу кем? Бу нәрсә? сорауларын аңлап, җавап бирә.
Әйбернең билгесен ачыклау максаты белән куела торган сорауны аңлый һәм сөйләмдә җавап кайтара белә.
Раслаучы, инкарь итүче сүзләрне дөрес кулланана белә.
Мин, син алмашлыкларын аңлый һәм урынлы куллана.
Кечкенә күләмле шигырьләр, җырлар белә.
Татар телендә сөйләшү теләге бар.

## 1.6 Зурлар төркеме (5-6 яшь)

## “Уйный – уйный үсәбез” проекты

**Лексик минимум** – якынча 45 сүз. “Уйный-уйный үсәбез” проекты темалары (“Гаилә”, “Ашамлыклар”, “Уенчыклар”, “Саннар” , “Яшелчәләр”, “Савыт-саба”, “Киемнәр”, “Шәхси гигиена”, “Өй җиһазлары”, “Бәйрәмнәр”) буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (уен, аралашу, музыка, хезмәт) ишетеп аңлап куллана белергә өйрәтү, сөйләм күнекмәләрен булдыру.

Яңа сүзләр хисабына баланың сөйләмен баету, тулыландыру. (*Кишер, суган, бәрәңге, кыяр, кәбестә, аш, ботка, кашык, тәлинкә,чынаяк, күлмәк, чалбар, бит, кул, өстәл урындык, карават, баллы, ничә, нинди, алты, җиде, сигез, тугыз, ун, кызыл, сары, яшел, зәңгәр, нәрсә кирәк, юа, ки, сал, йокла, хәерле көн, яратам, бар).*

Санау күнекмәләрен ныгыту, сөйләмдә камилләштерү.

Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? соравын аңлап, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белергә өйрәтү.

Раслаучы һәм инкарь итүче сүзләрне ныгыту, урынлы куллану. *(Әйе, юк)*

Исем + сыйфат конструкциясен сөйләмдә активлаштыру.

- *Бу кызыл тәлинкә.*

“Минем өем” проекты буенча өйрәнелгән боерык фигыльләрне ныгыту *(аша, эч, утыр, ю, уйна, йокла)*, яңа боерык фигыльләрне *(ки, сал)* сөйләмдә аңлап дөрес куллана белергә өйрәтү, активлаштыру.

Алган белемнәрен, сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә камилләштерү.

**Белем бирү эшчәнлегенең нәтиҗәләре**

Яңа сүзләр хисабына сүз байлыгы бар.

Үзара һәм зурлар белән көндәлек тормышта107 сүз кулланып татар телендә аралаша.

“Уйный-уйный үсәбез” проекты темалары (“Гаилә”, “Ашамлыклар”, “Уенчыклар”, “Саннар” , “Яшелчәләр”, “Савыт-саба”, “Киемнәр”, “Шәхси гигиена”, “Өй җиһазлары”, “Бәйрәмнәр”) буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (уен, аралашу, музыка, хезмәт) ишетеп аңлап куллана белә, сөйләм күнекмәләре бар.

Санау күнекмәләре бар, сөйләмдә куллана белә.

Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? соравын аңлап, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә.

Раслаучы һәм инкарь итүче сүзләрне аңлый, урынлы куллана.

Исем + сыйфат конструкциясен сөйләмдә дөрес куллана.

Боерык фигыльләрне сөйләмдә аңлап дөрес куллана белә.

Алган белемнәрен, сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә куллана белә.

## 1.7 Мәктәпкә әзерлек төркеме (6-7 яшь)

## “Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар”проекты

**Лексик минимум** – якынча 60 сүз. “Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар” проекты темалары ( “Гаилә”, “Ашамлыклар”, “Уенчыклар”, “Саннар” , “Яшелчәләр”, “Савыт-саба”, “Киемнәр”, “Шәхси гигиена”, “Өй җиһазлары”, “Бәйрәмнәр”, “Танышу”, “Тату гаилә”, “Дусларны сыйлыйбыз”, “Кунак килде”, “Кафега барабыз”, “Күңелле уеннар”, “Без циркта”, “Безнең дуслар”, “Чана шуабыз”, “Без биибез”, “Күңелле сәяхәт”,

“Мәктәп”, “Без әкият яратабыз”) буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (танып – белү, уен, аралашу, музыка, хезмәт) ишетеп аңлап куллана белергә өйрәтү, сөйләм күнекмәләрен булдыру.

Яңа сүзләр хисабына баланың сөйләмен баету, тулыландыру: *син кем, хәерле көн, тычкан, бу кем, бу нәрсә, нишли, йоклый, утыра, ашый, эчә, нишлисең, ашыйм, эчәм, уйный, уйныйм, утырам, барам, кая барасың, син нишлисең, сикер-сикерәм, сикерә, йөгерә, төлке, йөгер-йөгерәм, чәк-чәк, өчпочмак, яшь, бүре, керпе, тавык, әтәч, үрдәк, чана, шуа, шуам, бие, бии, биим, ак, кара, җырла-җырлыйм, зур рәхмәт, китап укый, рәсем ясыйм, укыйм, дәфтәр.*

Бу кем? Бу нәрсә? Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Нишли? Син нишлисең? Кая барасың? соравын аңлап, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белергә өйрәтү.

Алган белемнәрен, сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә камилләштерү. Монологик сөйләмне үстерү.

**Белем бирү эшчәнлеге нәтиҗәләре**

Яңа сүзләр хисабына сүз байлыгы бар.

Сөйләмне аралашу чарасы буларак файдалана белә.

Диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләре бар.

Үзара һәм өлкәннәр белән 167 сүз кулланып татар телендә актив аралаша.

“Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар” проекты темалары ( “Гаилә”, “Ашамлыклар”, “Уенчыклар”, “Саннар” , “Яшелчәләр”, “Савыт-саба”, “Киемнәр”, “Шәхси гигиена”, “Өй җиһазлары”, “Бәйрәмнәр”, “Танышу”, “Тату гаилә”, “Дусларны сыйлыйбыз”, “Кунак килде”, “Кафега барабыз”, “Күңелле уеннар”, “Без циркта”, “Безнең дуслар”, “Чана шуабыз”, “Без биибез”, “Күңелле сәяхәт”, “Мәктәп”, “Без әкият яратабыз”) буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (танып – белү, уен, аралашу, музыка, хезмәт) ишетеп аңлап куллана белә, сөйләм күнекмәләре бар.

Бу кем? Бу нәрсә? Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Нишли? Син нишлисең? Кая барасың? соравын аңлап, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белә.

Фигыльләрне урынлы куллана.

Җырлар, шигырьләр белә.

## II НЧЕ БҮЛЕК. Эчтәлек

## 2.1 Эш төрләре һәм формалары.

Программа бурычларын үтәүдә эш формаларының, практик гамәли алымнарның, чараларның әһәмияте зур. Төп эш төрләре булып түбәндәгеләр тора:

1. Предметлар белән эш: тасвирлау, уенчык белән диалог төзү, уен һәм әкиятләрдә катнашу.
2. Рәсемнәр белән эш: тасвирлау, үстерешле диалог.
3. Сюжетлы-рольле уеннар;
4. Әйлән-бәйлән, җырлы-биюле уеннар өйрәнү (аудиоязмага таянып).
5. Театральләштерү, сәхнәләштерү (бармак театры, битлекләр, костюмнар, театр күрсәтү (әти-әниләргә, башка төркем балаларына).
6. Хәрәкәтле уеннар: туп белән уеннар, “Командир” уены, әйлән-бәйлән уен, зарядка уеннары.
7. Иҗади һәм ситуатив уеннар: рольле уеннар, интервью, ситуатив күнегүләр.

8. Ситуатив, логик күнегүләрне ишетеп, аңлап эшләү.
9. Үстерелешле диалоглар (зурлар һәм яшьтәшләре белән үзара аралашу).
10. Аудиоязмалар тыңлау, кушылып әйтү, җырлау, кабатлау, ишеткән сүзне рәсемдә табып күрсәтү.
11. Анимацион сюжетлар, мультфильмнар карау.
12. Интерактив уеннар.

## 2.2 Инновацион эш

Яшәешне электрон технологияләре чолгап алган бу заманда балаларга белеем бирү процессы да үзгәрешсез кала алмый. Берничә дистә телеканалдан мультфильмнар карауга, компьютер уеннарына күнегеп беткән балалар өчен, аларның кабул итү мөмкинлекләренә туры килгән яңа чаралар уйлап табу - заман таләбе.

Рус балаларына татар теле өйрәтүдә интерактив такта балаларга белем бирү өчен иң мөһим интерактив инструментларның берсе булып тора. Аның ярдәмендә эшчәнлекне кызыклы һәм мавыктыргыч итеп оештырырга мөмкин. Интерактив такта төрле мультимедия ресурсларда бирелгән мәгълүматларны файдаланырга, комментарийлар кулланырга, эшчәнлекне өстәмә мәгълүматлар белән баетырга мөмкинлек бирә. Уенчыклар, рәсемнәр кулланып яки ковролинда аңлатып булмаган материалны нәкъ менә интерактив такта ярдәмендә бирергә була. Мондый тактада булган һәрбер объктны күчереп йөртергә, тиз арада яңа рәсемнәр ясарга, аларга төсләр бирергә, үзгәртергә һәм бетерергә, белем бирүдә ике яклы диалогка ирешергә (интерактив такта- бала), интернеттагы ресурслардан файдаланырга мөмкин (видео материал карау).

Баланың күз алдында барган динамик үзгәрешләр: экрандагы хәрәкәт, төс, тавыш информация бирүне аңлаешлы һәм кызыклы , ә балаларны игътибарлы булырга мәҗбүр итә, шуңа күрә тема барлык балаларга да җиткерелә дип уйларга нигез бар.

Тәҗрибәләр күрсәткәнчә, интерактив такта куллану балаларның өйрәнә торган тема белән кызыксыну дәрәҗәсе артуына китерә һәм телне өйрәнү теләкләрен дә арттыра.

« Информацион- коммуникатив технологияләрне мәктәпкәчә яшьтәге балаларның танып-белү эшчәнлекләрен һәм телен үстерүдә куллану» программасын тормышка ашыру өчен бөтен мөмкинлекләр дә тудырылган.

Барлык педагоглар да SMART NOTEBOOK, Microsoft Power Point программаларында меток эшкәртмәләр ясау һәм компьютерны өйрәнү буенча курслар үттеләр. Санитар-гигиеник таләпләргә туры килгән махсус җиһазландырылган кабинет бар.

“Увлекательное обучение” методик эшкәртмәсендә уртанчылар, зурлар һәм мәктәпкә әзерлек төркеме балалары өчен интерактив уеннар эшкәртмәләре, эшчәнлек конспектлары бирелгән.

## 2.3 Ата- аналар белән бәйләнеш

| | | |
|---|---|---|
| Кечкенәләр төркеменә яңа килгән татар милләтеннән булган балаларның ата-аналары белән анкета үткәрү. | сентябрь | ГайнутдиноваА.М |
| Уртанчылар төркеме балаларының ата-аналары җыелышында “Татарча сөйләшәбез” укыту-методик комплектын кулланып 4-5 яшьлек балаларны татар теленә өйрәтү” темасына чыгыш ясау. | сентябрь | ГайнутдиноваА.М. |
| Консультация: “Татарча сөйләшәбез” укыту-методик комплектын һәм инновацион технологияләр кулланып балаларны татар теленә өйрәтү” | октябрь | ГайнутдиноваА.М |
| Ачык ишекләр көне:<br>Уртанчылар, зурлар , мәктәпкә әзерлек төркеме балалары белән оештырулы белем бирү эшчәнлеге күрсәтү. | ноябрь | ГайнутдиноваА.МТ өркем тәрбиячеләре |
| Балалар бакчасының сайтында укыту-методик комплекты турындагы мәгълүматларны яңартып тору. | ел дәвамында | Гайнутдинова А.М. |
| Төркемнәрдә “Татарча сөйләшәбез – Говорим по – татарски” исемле ата-аналар почмакларындагы һәм папкалардагы мәгълүматларны яңартып тору. | ел дәвамында | Гайнутдинова А.М. |
| Ата –аналар белән шәхси консультацияләр һәм әңгәмәләр үткәрү. | ел дәвамында | Гайнутдинова А.М. |
| “Күңелле Сабантуй” темасына балалар һәм ата-аналар белән берлектә рәсем күргәмәсе , “Сабан туй “ бәйрәме оештыру. | июнь | Гайнутдинова А.М. Төркем тәрбиячеләре |

## 2.4 Коррекция эше

### Уртанчылар төркеме (4-5 яшь)

### “Минем өем “ проекты

| Үткәрү вакыты | Сораулар, биремнәр | Уеннар, күнегүләр, биремнәр | төркем | Баланың исем, фамилиясе |
|---|---|---|---|---|
| Октябрь | “Минем өем” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. Бу кем? соравына җавап бирү. Ягымлы сүзләр кулану: (“Исәнме”, “Исәнмесез”, “Сау бул”, “Сау | 1. Дидактик уеннар: “Бу кем?”, “Матур өйдә кем яши?”, “Кем юк”(әйе – юк), “Исемен әйтсәң бирәм” (гаилә әгзалары).<br>2.Бармак уены: “Гаилә”.<br>3.Ситуатив күнегү: “Аю куянга кунакка килә”. | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | булыгыз”, “Рәхмәт”) | | | |
| Ноябрь | Ягымлы сүзләр кулану: (“Исәнме”, “Исәнмесез”, “Сау бул”, “Сау булыгыз”, “Рәхмәт”) Бу нәрсә? соравына җавап бирү | 1.Ситуатив күнегү: “Аю куянга кунакка килә”. 2. Дидактик уеннар: “Кәрзиндә нәрсә бар”, “Нәрсә юк”. 3.Уен ситуациясе: “Акбайны, Мияуны сыйла”, “Дустыңны сыйла”. | | |
| Декабрь | Бу нәрсә? соравына җавап бирү. Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу) | 1.Дидактик уеннар: “Бу нәрсә?”, “Серле тартма”, “Акбайны сыйла”, “Мияуны сыйла”, “Чәй, сөт белән сыйла”, “Курчакны макта”. 2.Сүзле уен: “Туп” 3. Сюжетлы-рольле уен: “Уенчыклар кибете”. | | |
| Январь | Бу нәрсә? соравына җавап бирү. Боерык бирә белү (кил монда, утыр, аша, эч) | 1.Дидактик уеннар: “Серле тартма”, “Әйт, нинди уенчык”, “Сорап ал, уйна”, 2.Җырлы-биюле уен: “Карусель”. 3.Хәрәкәтле уен: “Мин кушканны үтә, әйт”. | | |
| Февраль | Тирә - юньдәге предметларның сыйфатын, күләмен белдерә торган сүзләрне аңлап сөйләмдә куллану. | 1.Дидактик уеннар: “Уенчыклар юабыз”, ”Уенчык нинди?” “Барысы ничә?”, ”Дөрес итеп сана”, “Гаилә әгъзаларын сана, ничә?” 2.Сюжетлы-рольле уен: “Уенчыклар кибете”. | | |
| Март | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, | 1.Уен ситуациясе: “Әйдә, танышыйк”. “Кунак каршылау”. “Кунак сыйлау”. ”Уенчык сорап ал”. | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | инкаръ итү, раслау) | “Курчакны макта!” | | |
| Апрель | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкаръ итү, раслау) | 1.Уен ситуациясе: “Акбай белән Мияу бер-берсен сыйлыйлар”. “Акбай белән Мияу балаларны сыйлыйлар”. 2.Сүзле уен: “Рәхмәт әйт”. 3.Дидактик уеннар: “Тылсымлы тартма”, “Барысы ничә?” 4.Хәрәкәтле уен: “Мин кушканны үтә” | | |
| Май | Татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү | | | |

**Зурлар төркеме (5-6 яшь)**
**“Уйный – уйный үсәбез” проекты**

| Үткәрү вакыты | Сораулар, биремнәр | Уеннар, күнегүләр, биремнәр | төркем | Баланың исем, фамилиясе |
|---|---|---|---|---|
| Октябрь | “Уйный-уйный үсәбез” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. Бу кем? Бу нәрсә? Нинди? Ничә? сорауларына җавап бирү | 1.Дидактик уеннар: “Бу нәрсә?”, “Бу кем?”, “Нинди? Ничә?”, “Дөресен әйт”, “Кем юк?” | | |
| Ноябрь | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкарь итү, раслау) | 1.Ситуатив күнегү: “Яшелчәләр кибете”. 2.Уен ситуация: "Дустыңны сыйла". 3.Дидактик уеннар: “Нинди төс юк?”, “Сорап ал”, “Дөрес әйтсәң бирәм”, “Яшелчә ю”, “Нәрсә, нинди, ничә?” | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Декабрь | Боерык бирә белү(кил монда, утыр, уйна, ю, аша, эч, ки, сал, йокла) | 1.Дидактик уеннар: “Командир”, “Нәрсә юк?” (киемнәр, яшелчәләр, савыт-саба), “Сыйла”, “ Савыт-саба сайлыйбыз | | |
| Январь | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкарь итү, раслау) | 1.Дидактик уеннар: “Нәрсә юк?” (киемнәр, яшелчәләр, савыт-сабалар), “Мин әйтәм, син эшлә” 3.Сюжетлы-рольле уен: “Савыт-саба кибете”, | | |
| Февраль | Уен ситуацияләрендә үзлектән сорау куя белү (Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Син кем?) Киемнәр, савыт-сабалар лексикасын ныгыту. | 1.Дидактик уеннар: “Тыңла,күрсәт, кабатла”, “Курчак Алиягә булыш”. 2.Сюжетлы-рольле уен: “Киемнәр кибете”. | | |
| Март | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкарь итү, раслау) | 1.Сюжетлы- рольле уеннар: “Савыт-саба кибете”, “Супермаркет”, ”Туган көн”. 2.Дидактик уен: “Парын тап» (төсләр) | | |
| Апрель | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкарь итү, раслау) | 1.Уен ситуациясе: “Таныш булыйк”, “Кәрзиндә нәрсә бар?”, “Алиягә киенергә булыш”, “Аюлар яңа өйгә күчә, булыш” ”Савыт-сабалар бүләк итәбез” | | |
| Май | Татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү | | | |

**Мәктәпкә әзерлек төркеме (6-7 яшь)**
**“Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар” проекты**

| Үткәрү вакыты | Сораулар, биремнәр | Уеннар, күнегүләр, биремнәр | төркем | Баланың исем, фамилиясе |
|---|---|---|---|---|
| Октябрь | “Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. Бу кем? Бу нәрсә?сорауларына җавап бирү | 1.Дидактик уеннар: “Бу нәрсә?” “Бу кем?” “Нишли?” “Нишлисең?” “Кем юк?”. | | |
| Ноябрь | Ягымлы сүзләр куллану (“Исәнме”, “Исәнмесез”, “Сау бул”, “Сау булыгыз”, “Рәхмәт”, “Зур рәхмәт”, “Хәерле көн”,“Хәлләр ничек?”, “Әйбәт”) | 1.Ситуатив күнегү: “Телефоннан сөйләшү”. 2.Уен ситуация: “Дустыңны сыйла”, “Кая барасың?” | | |
| Декабрь | Боерык бирә белү(кил, утыр, сикер, йөгер уйна, ю, аша, эч, ки, сал, йокла). Уен ситуацияләрендә үзлектән сорау куя белү. | 1.Дидактик уеннар: “Командир”, “Үзең турында сөйлә”, “Билет сатып ал”, “Нишли?”, “Интервью бирәбез” | | |
| Январь | Уен ситуацияләрендә үзлектән сорау куя белү. | 1.Дидактик уеннар: “Нишли”, “Бу нәрсә?”, “Телефоннан сөйләшү” | | |
| Февраль | Уен ситуацияләрендә үзлектән сорау куя белү: Син кем? Бу кем? Бу нәрсә? Нишли? Ничә яшь? Сиңа ничә яшь? | 1.Дидактик уеннар: “Бу нәрсә”, “Нишли?”, “Телефоннан сөйләшү”, “Үзең турында сөйлә”, “Син нишлисең?” | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Нишлисең? Син нишлисең? Кая барасың? | | | |
| Март | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкарь итү, раслау) | 1.Уен ситуациясе “Таныш булыйк”.<br>2.Дидактик уеннар: “Портфельдә нәрсә бар?”, “Портфельдә нәрсә юк?”, “Теремкәйдә кем яши?”, ”Урман мәктәбе” .<br>3.Сүзле уен: “Сорауга җавап бир”.<br>4.Үстерелешле диалог: “Телефоннан сөйләшәбез”. | | |
| Апрель | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкарь итү, раслау) | 1.Җырлы-биюле уен: “Минем өем”,<br>2.Сүзле уеннар: “Син кем?”, “Үзең турында сөйлә”, “Хәерле көн”, “Ягымлы сүзләр”, “Сорауга җавап бир”.<br>3.Дидактик уеннар: “Нишли”, “Син нишлисең?”,<br>4.Сюжетлы-рольле уен: “Сыйлану” | | |
| Май | Татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү | | | |

## III НЧЕ БҮЛЕК. Оештыру

## 3.1 Материаль - техник яктан тәэмин ителеш

| | | |
|---|---|---|
| Татар теле кабинеты | Белем бирү эшчәнлеге, индивидуаль, коррекцион эш, ата-аналар, педагоглар өчен консультацияләр, ачык эшчәнлекләр . | Зурлар һәм балалар өчен өстәлләр, урындыклар, компьютер, принтер, интерактив такта, ноутбук, магнитофон, уенчыклар, дидактик, интерактив уеннар, балалар әдәбияты, тематик папкалар, альбомнар, укыту -методик комплект (демонстрацион, таратма материал, аудио, видео дисклар, маскалар, театрларның төрле төрләре),ТР һәм РФ символикасы. |

## 3.2 Предметлы - үстерелешле әйләнә тирәлек

**Эш дәфтәрләре**

Зарипова З.М.“Татарча сөйләшәбез”. 4-5 яшьлек балалар өчен эш дәфтәре, “Хәтер”, 2012
Зарипова З.М.“Татарча сөйләшәбез”. 5-6 яшьлек балалар өчен эш дәфтәре, “Хәтер”, 2012
Зарипова З.М. “Татарча сөйләшәбез”. 6-7 яшьлек балалар өчен эш дәфтәре, “Татарстан китап нәшрияты”, 2012

**Тавышлы күрсәтмәлелек**

Зарипова З.М. “Минем өем” проеты буенча 4-5 яшьлек балалар өчен укыту-методик комплектына аудиоязмалар. “Аксу” компаниясе, 2012
Зарипова З.М. “Уйный- уйный үсәбез” проекты буенча 5-6 яшьлек балалар өчен укыту-методик комплектына аудиоязмалар. “Аксу” компаниясе, 2012
Зарипова З.М. “Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар”, проекты буенча 6-7 яшьлек балалар өчен укыту-методик комплектына аудиоязмалар. “Аксу” компаниясе, 2012
Зарипова З.М. “Минем өем” проекты буенча 4-5 яшьлек балалар өчен анимацион сюжетлар. “Аксу” компаниясе, 2012
Зарипова З.М. “Уйный- уйный үсәбез” проекты буенча 5-6 яшьлек балалар өчен анимацион сюжетлар. “Аксу” компаниясе, 2012

**Күрсәтмә, таратма материаллар, театр эшчәнлеге өчен атрибутлар.**
**“Минем өем” проекты буенча 4-5 яшьлек балалар өчен**

| | | |
|---|---|---|
| 1.А №4 форматында күрсәтмә рәсемнәр | “Минем гаилә”<br>Бабай, әби, әти, әни, малай, кыз. | Һәрберсе 1 данә |
| | Зур уенчыклар: курчак, куян, аю, туп, песи, эт, машина.<br>Кечкенә уенчыклар: курчак, куян, аю, туп, песи, эт, машина. | Һәрберсе 1 данә |
| | “Ашамлыклар”<br>Ипи, алма, чәй, сөт. | Һәрберсе 1 данә |
| | “Уенчыклар” | Һәрберсе |

| | | |
|---|---|---|
| | Курчак, куян, аю, туп, песи, эт, машина.<br>курчак, куян, аю, туп, песи, эт, машина – пычрак уенчыклар. | 1 данә |
| | Сюжетлы рәсемнәр: “Куян өйгә керә, өйдә аю утыра”. “Куян өйдән чыга, саубуллаша”. | Һәрберсе<br>1 данә |
| | Рәсемнәр: 1 куян, 2 куян, 3 куян, 4 куян, 5 куян;<br>1 аю, 2 аю, 3 аю, 4 аю, 5 аю;<br>1 курчак, 2 курчак, 3 курчак, 4 курчак, 5 курчак;<br>1 туп, 2 туп, 3 туп, 4 туп, 5 туп;<br>1 машина, 2 машина, 3 машина, 4 машина, 5 машина;<br>1 песи, 2 песи, 3 песи, 4 песи, 5 песи;<br>1 эт, 2 эт, 3 эт, 4 эт, 5 эт. | Һәрберсе<br>1 данә |
| 2.А №3 форматында өй рәсеме | Өй макеты | 1 данә |
| 3. А №5 форматында таратма рәсемнәр | “Минем гаилә”<br>Бабай, әби, әти, әни, малай, кыз. | Һәрберсе<br>15 данә |
| | “Ашамлыклар”<br>Ипи, алма, чәй, сөт. | Һәрберсе<br>15 данә |
| | “Уенчыклар”<br>Курчак, куян, аю, туп, песи, эт, машина. | Һәрберсе<br>15 данә |
| 4. Театр эшчәнлеге өчен атрибутлар | Битлекләр: бабай, әби, әти, әни, малай, кыз, куян, аю, песи, эт. | Һәрберсе<br>15 данә |
| Бармак уеннары өчен атрибутлар | бабай, әби, әти, әни, малай, кыз, эт Акбай, песи Мияу, аю, куян. | Һәрберсе<br>15 данә |

**“Уйный-уйный үсәбез” проекты буенча 5-6 яшьлек балалар өчен**

| | | |
|---|---|---|
| 1. Күрсәтмә рәсемнәр | “Минем гаилә”<br>Малай, кыз рәсемнәре, “Курчакны киендер” уены. Кыз, малай өчен киемнәр: күлмәк (кызларныкы, малайларныкы), футболка, шорты, чалбар, сарафан - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе<br>1 данә |
| | “Уенчыклар”<br>Зур уенчыклар: курчак, туп, машина - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).<br>Кечкенә уенчыклар: курчак, туп, машина - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе<br>1 данә |
| | “Ашамлыклар”<br>Аш, ботка, чәк-чәк, конфет, сок. | Һәрберсе<br>1 данә |

| | | |
|---|---|---|
| | “Савыт-саба”<br>Зур рәсемнәр: кашык, тәлинкә, чынаяк - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).<br>Кечкенә рәсемнәр: кашык, тәлинкә, чынаяк - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе 1 данә |
| | “Җиләк-җимешләр”<br>Зур рәсемнәр: яшел алма, сары, кызыл, банан, апельсин, виноград, груша.<br>Кечкенә рәсемнәр: яшел алма, сары, кызыл, банан, апельсин, виноград, груша. | Һәрберсе 1 данә |
| | “Яшелчәләр”<br>Зур рәсемнәр: кишер, бәрәңге, суган, кыяр, кәбестә.<br>Кечкенә рәсемнәр: кишер, бәрәңге, суган, кыяр, кәбестә. | Һәрберсе 1 данә |
| | “Киемнәр”<br>Зур рәсемнәр: күлмәк (кызларныкы, малайларныкы), чалбар - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).<br>Кечкенә рәсемнәр: күлмәк (кызларныкы, малайларныкы), чалбар - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе 1 данә |
| | “Өй җиһазлары”<br>Зур рәсемнәр: карават, урындык, өстәл - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).<br>Кечкенә рәсемнәр: карават, урындык, өстәл - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе 1 данә |
| | “Төсләр”<br>Палитра: зәңгәр, кызыл, сары, яшел. | Һәрберсе 1 данә |
| | “Саннар” (1дән 10га кадәр) | Һәрберсе 1 данә |
| 2. Таратма рәсемнәр | “Минем гаилә”<br>Малай, кыз рәсемнәре, “Курчакны киендер” уены. Кыз, малай өчен киемнәр: күлмәк (кызларныкы, малайларныкы), футболка, шорты, чалбар, сарафан - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе 15 данә |
| | “Уенчыклар”<br>Зур уенчыклар: курчак, туп, машина - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).<br>Кечкенә уенчыклар: курчак, туп, машина - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе 15 данә |
| | “Ашамлыклар”<br>Аш, ботка, чәк-чәк, конфет, сок. | Һәрберсе 15 данә |
| | “Савыт-саба”<br>Зур рәсемнәр: кашык, тәлинкә, чынаяк - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).<br>Кечкенә рәсемнәр: кашык, тәлинкә, чынаяк - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе 15 данә |

| | | |
|---|---|---|
| | “Җиләк-җимешләр”<br>Зур рәсемнәр: яшел алма, сары, кызыл, банан, апельсин, виноград, груша.<br>Кечкенә рәсемнәр: яшел алма, сары, кызыл, банан, апельсин, виноград, груша. | Һәрберсе 15 данә |
| | “Яшелчәләр”<br>Зур рәсемнәр: кишер, бәрәңге, суган, кыяр, кәбестә.<br>Кечкенә рәсемнәр: кишер, бәрәңге, суган, кыяр, кәбестә. | Һәрберсе 15 данә |
| | “Киемнәр”<br>Зур рәсемнәр: күлмәк (кызларныкы, малайларныкы), чалбар - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).<br>Кечкенә рәсемнәр: күлмәк (кызларныкы, малайларныкы), чалбар - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе 15 данә |
| | “Өй җиһазлары”<br>Зур рәсемнәр: караваt, урындык, өстәл - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).<br>Кечкенә рәсемнәр: кровать, стул, стол - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе 15 данә |
| 3.Буяу өчен график рәсемнәр | 1 аю, 2 куян, 2 машина, 2 курчак, 3 бәрәңге, 4 кәбестә, 4 курчак, 5 песи, 6 алма, 6 кыяр, 7 туп, 7 бәрәңге, 8 кишер, 9 суган, 10 эт. | Һәрберсе 15 данә |
| 4.Театр эшчәнлеге өчен атрибутлар | Битлекләр: кишер, суган, кыяр, бәрәңге, кәбестә, алма. | Һәрберсе 15 данә |
| 5. Театр эшчәнлеге өчен атрибутлар | 1.Өстәл театры өчен атрибутлар (конус формасында): “Өч аю”: әти аю, әни аю, бала аю.<br>2. Өстәл театры өчен атрибутлар (конус формасында): “Кем нәрсә ярата”: песи, эт, аю, куян, кәҗә, әтәч.<br>өстәл (зур, уртача зурлыкта, кечкенә);<br>урындык (зур, уртача зурлыкта, кечкенә);<br>караваt (зур, уртача зурлыкта, кечкенә). | Һәрберсе 1 данә<br><br>Һәрберсе 1 данә |

**“Без инде хәзер зурлар-мәктәпкә илтә юллар” проекты буенча
6-7 яшьлек балалар өчен**

| | | |
|---|---|---|
| 1.А №4 форматында күрсәтмә рәсемнәр | Үрдәк, бүре, әтәч, тавык, зур тычкан, кечкенә тычкан, китап, альбом, клей, линейка, ручка, карандаш, пенал, дәфтәр, кофе, пицца, бәрәңге фри, өчпочмак. | Һәрберсе 1 данә |
| | Шарлар - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе 1 данә |
| | Сюжетлы рәсемнәр: куян чана шуа, аю чана шуа, бүре чана шуа, төлке чана шуа, үрдәк чана шуа, тавык чана шуа, тычкан чана шуа, төлке бии, керпе йоклый, бүре йөгерә, | Һәрберсе 1 данә |

| | | |
|---|---|---|
| | төлке утыра, керпе уйный, аю йоклый, песи сөт эчә, эт ашый, төлке йөгерә, куян сикерә, тычкан ашый, әтәч җырлый, кыз кул юа, малай китап укый, кыз китап укый, төлке китап укый, куян китап укый, әни кул юа, әти йоклый, малай утыра, кыз бит юа, әби утыра, бабй йоклый. | |
| 2. А №5 форматында таратма рәсемнәр | Үрдәк, бүре, әтәч, тавык, зур тычкан, кечкенә тычкан, китап, альбом, клей, линейка, ручка, карандаш, пенал, дәфтәр, кофе, пицца, бәрәңге фри, өчпочмак. | Һәрберсе 15 данә |
| | Шарлар - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе 15 данә |
| | Сюжетлы рәсемнәр: куян чана шуа, аю чана шуа, бүре чана шуа, төлке чана шуа, үрдәк чана шуа, тавык чана шуа, тычкан чана шуа, төлке бии, керпе йоклый, бүре йөгерә, төлке утыра, керпе уйный, аю йоклый, песи сөт эчә, эт ашый, төлке йөгерә, куян сикерә, тычкан ашый, әтәч җырлый, кыз кул юа, малай китап укый, кыз китап укый, төлке китап укый, куян китап укый, әни кул юа, әти йоклый, малай утыра, кыз бит юа, әби утыра, бабай йоклый. | Һәрберсе 15 данә |
| 8х10 форматында пиктограммалар | Бии, йоклый, утыра, ашый, эчә, уйный, сикерә, йөгерә, укый, рәсем ясый, җырлый, чана шуа, мин, кыз, малай, әби, бабай. | Һәрберсе 15 данә |
| 15х20 форматында пиктограммалар | Бии, йоклый, утыра, ашый, эчә, уйный, сикерә, йөгерә, укый, рәсем ясый, җырлый, чана шуа, мин, кыз, малай, әби, бабай, куян, төлке, песи, эт, аю, әтәч, тавык, үрдәк, керпе, тычкан | Һәрберсе 1 данә |

## 3.3 Программалар белән һәм методик яктан тәэмин ителеш

Зарипова З.М. Балалар бакчасында рус балаларына татар теле өйрәтү программасы. “Идел-Пресс”, 2013.

Зарипова З.М “Татарча сөйләшәбез”. 4-5 яшьлек балаларны татар теленә өйрәтү буенча методик ярдәмлек, “Хәтер”, 2011

Зарипова З.М. “Татарча сөйләшәбез”. 5-6 яшьлек балаларны татар теленә өйрәтү буенча методик ярдәмлек, “Хәтер”, 2012

Зарипова З.М. “Татарча сөйләшәбез”. 6-7 яшьлек балаларны татар теленә өйрәтү буенча методик ярдәмлек, “Татарстан китап нәшрияты”, 2012

Нургалиева М.С. “Увлекательное обучение”. Использование интерактивной доски при обучении дошкольников государственным языкам, 2013

Нургалиева М.С. “Дидактические игры по обучению русскоязычных детей 4 – 7 лет татарскому языку”. 2013